КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 июнь г.Казань № 510

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2019 ел, 28 август, 731 нче карары белән расланган Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2019 ел, 28 август, 731 нче карары белән расланган Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Граждан кодексы;

Россия Федерациясе Җинаять кодексы;

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Элемтә турында» 2003 елның 7 июлендәге 126-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны яклау хакында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 30 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы мәсьәләләре» 2004 елның 11 июлендәге 868 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе территориясендә ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын камилләштерү турында» 2010 елның 28 декабрендәге 1632 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аларны тәүлек буе һәм бушлай чакыру элемтә операторын элемтә хезмәтләреннән файдаланучыга тәэмин итәргә тиеш ашыгыч оператив хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2021 елның 31 августындагы 1453 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү системасын оештыру һәм эшләтүгә мәҗбүри таләпләрне, шул исәптән бердәм «112» номеры буенча чакыруларны кабул итү, эшкәртү һәм тапшыру тәртибен һәм срокларын раслау турында» 2021 елның 12 ноябрендәге 1931 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү системаларының көчләре һәм чараларының үзара хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 27 ноябрендәге 2071 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 1240-б номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Элемтә хезмәтеннән файдаланучылар тарафыннан ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы

территориясендә бердәм «112» номерын куллану турында» 2014 елның 7 апрелендәге 74 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Россия нумерация системасын һәм планын раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2017 елның 25 апрелендәге 205 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2021 елның 6 октябрендәге 681н номерлы боерыгы;

ГОСТ Р 22.7.01-2021 «Гадәттән тыш хәлләрдә хәвефсезлек. Бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте. Төп нигезләмәләр»;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Төнге вакытта гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кичектергесез чакырулар хезмәте – 112» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2014 ел, 13 август, 588 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, Гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторлары) кертелмәгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 октябрь, 2114-б номерлы боерыгы.»;

әлеге карар белән расланган Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин